Казан
(Идел буе)
федераль
университеты
газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№ 22
(115)

29 август
2014 ел

12+




*Бел : гыйлем – нур ул,*
*сине нурландырыр,*
*Ә наданлык – ут,*
*сине ул яндырыр!*

Габдерәхим Утыз Имәни

www.kpfu.ru

чыгарылышның
электрон версиясе

UNIVERSMOTRI.RU




## Хөрмәтле беренче курс студентлары!

Сез быел 210 яшен тутырачак, Россиядә иң борынгы уку йортларының берсе булган университетның бусагасын атлап кердегез. Хәзер университетыбызның, федераль дәрәҗәдәге уку йорты буларак, сезгә заманча белем бирү өчен генә түгел, тормыштагы барлык өлкәләрдә көндәшлеккә сәләтлелегегезне көчәйтә торган өстәмә күнекмәләр бирү өчен дә мөмкинлекләре артты.

Безнең университет структуралары ватаныбыз һәм чит ил партнерлары белән тыгыз бәйләнештә торган эре фәннибелем бирү холдингына әйләнде. Хезмәттәшлек, академик өлкә белән беррәттән, уртак кафедралар, лабораторияләр, җитештерү үзәкләре, кече инновацион предприятиеләр кысаларында, шул ук вакытта икътисадның реаль секторында да алып барыла.

КФУның партнерлары булып, 50 илдәге 160тан артык вуз һәм фәнни үзәкләр тора. Алар арасында шулай ук РИКЕН, Сорбонна, Нью-Йорк Штаты университеты һ.б. фәнни үзәкләр дә бар. Университетыбыз уртак магистратура, «икеләтә диплом», «икеләтә яклау» программаларын гамәлгә ашыра.

Кискен көндәшлек шартларында Казан федераль университеты илебезнең 14 алдынгы уку йорты рәтендә «Глобаль көндәшлеккә сәләтлелек» проектында катнашу хокукына ия булды. Әлеге проектның максаты – Россиянең биштән ким булмаган университетын ТОП-100 дөньяви вузлар рейтингына кертү. Әйтергә кирәк, барлык федераль университетлардан КФУ гына һәр елны үз позицияләрен Россия һәм дөньяви рейтингларда ныгыта.

Бүген заман бик тиз үзгәрә, шуңа сез үзгәрүчән һәм конкурентлы икътисад шартларына яраклашкан, теләсә нинди эштә уңышка омтыла һәм аңа ирешә торган универсаллар булырга тиеш.

Студент тормышы – уку һәм фән генә түгел. Ул төрле мәдәни вакыйгаларга һәм яшьләр өчен якты бәйрәмнәргә бай. Уку йортындагы тормышыгызның беренче көннәреннән үк тәвәккәлләп эшкә керешсәгез иде, яшь дусларым! Куйган максатларыгызга омтылыгыз һәм сез барысына да ирешәчәксез. Мин сезгә укуда, фәндә, спортта, иҗатның төрле өлкәләрендә уңышлар, тормышта лаеклы урын табуыгызны телим! Россиянең иң яхшы уку йортларының берсендә укуыгыз белән һәрвакыт горурланыгыз!

**Илшат Гафуров, КФУ ректоры**

## Университет җитәкчелеге



Уку-укыту эшләре буенча проректор - **Минзарипов Рияз Гатауллович**
☎ 233-70-03
✉ riaz.minzaripov@kpfu.ru , uno_ksu@mail.ru



Фәнни эшчәнлек буенча проректор - **Нургалиев Данис Карлович**
☎ 292-72-88
✉ danis.nourgaliev@kpfu.ru



Административ эшләр буенча проректор - аппарат җитәкчесе - **Хашов Андрей Николаевич**
☎ 292-73-26
✉ a-ha1964@mail.ru




Икътисади һәм стратегик үсеш буенча проректор - **Сафиуллин Марат Рәшитович**
☎ 292-78-57,
✉ lgudyaev@kpfu.ru , marat.safiullin@tatar.ru




Финанс эшләре буенча проректор - **Муллакаева Рәйсә Рифовна**
☎ 233-70-71
✉ raisa.mullakaeva@kpfu.ru




Хуҗалык эшләре буенча проректор – **Сафиуллин Ленар Солтангалиевич**
☎ 233-74-06
✉ lenar.safiullin@kpfu.ru



Социаль һәм тәрбия эшчәнлеге буенча проректор – **Межведилов Ариф Магидинович**
☎ 233-74-29, 292-72-26
✉ amezhved@mail.ru




Тышкы элемтәләр буенча проректор – **Латыйпов Линар Наилевич**
☎ 233-74-47
✉ linar.latypov@kpfu.ru




Инновацион эшчәнлек буенча проректор - **Кашапов Наил Фаикович**
☎ 233-78-71
✉ kashnail@gmail.com

## Институт директорлары




**Андрей Павлович Киясов,** Фундаменталь медицина һәм биология институты директоры




**Светлана Юрьевна Селивановская,** Экология һәм география институты директоры




**Данис Карл улы Нургалиев,** Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты директоры



**Рамил Равил улы Хәйретдинов,** Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты директоры




**Владимир Аркадьевич Чугунов,** Н.И.Лобачевский исемендәге Математика һәм механика институты директоры



**Альберт Вартанович Аганов,** Физика институты директоры




**Владимир Иванович Галкин,** А.М.Бутлеров исемендәге Химия институты директоры



**Илдар Габделхак улы Тарханов,** Юридик факультет деканы



**Рөстәм Хафиз улы Латыйпов,** Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты директоры




**Рәдиф Рифкать улы Җамалетдинов,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры




**Михаил Дмитриевич Щелкунов,** Социаль-фәлсәфә фәннәре һәм гаммәви коммуникацияләр институты директоры



**Айдар Миңнемансур улы Кәлимуллин,** Психология һәм белем бирү институты директоры




**Искәндәр Шамил улы Галеев,** Физик тәрбия һәм спорт институты директоры




**Айрат Фәрит улы Хәсьянов,** Мәгълүмати технологияләр һәм системалар югары мәктәбе директоры



**Наилә Гомәр кызы Баһаутдинова,** Идарә, икътисад һәм финанслар институты директоры




**Кузнецова Ирина Борисовна,** Җәмгыятьнең модернизацияләнүен чагыштырып тикшерү институты директоры



**Наил Фаик улы Кашапов,** Инженерия институты директоры



**Мәхмүт Мәсхүт улы Ганиев,** Политехник институт директоры



**Елена Ефимовна Мерзон,** Алабуга институты директоры




## «Авыл» эче – имин йорт

Кемдер тулай торакта, кемдер кампуста, кемдер студент шәһәрчегендә яши. Ә КФУга укырга кергән беренче курс студентлары «авылда» яши. Гади генә түгел әле үзе! 2013 елда XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиада уеннарына килгән спортчылар яшәгән «авыл». Универсиада авылы! Авылда тормыш бик күңелле үтә. Заманча җиһазландырылган бүлмәләрдә яшәүдән тыш, монда син үз талантларыңны да үстерә алачаксың. Универсиада авылы студентлар ассоциациясе инде үз талантлары, уңышлары белән мактана ала. Аны оештыручылар яңа сәләтле яшьләргә бик шат булачак. Шуңа күрә үз осталыкларыңны күрсәтергә оялып торма, авылдашларыңнан калышма! Моның өчен студентлар үзидарәсе кураторлары **Илсур Хисмәтуллинга** **(тел: 8-917-247-11-19, e-mail: i.hismatullin@mail.ru)** һәм **Евгений Романовка** **(тел.: 8-917-396-59-77, e-mail: zheka1211@mail.ru)**, Универсиада авылы студентлар ассоциациясе рәисе **Адина Кульмасовага** **(тел: 8-951-065-70-22 һәм 8-912-743-19-56, e-mail: adina.russianfun@mail.ru)** һәм Студентлар шәһәрчегенең Берләшкән студентлар советы рәисе **Дамир Әхмәтшинга** **(тел: 8-929-725-89-89)** мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Универсиада авылыннан тыш КФУ студентлары шулай ук Кызыл Позиция һәм Г.Кутуй урамнарында урнашкан студентлар шәһәрчегендә, Пушкин ур., 32 а һәм Губкин ур., 11 адреслары буенча «Студентлар йорты»нда һәм Бутлеров ур., 6 адресындагы тулай торакта да яшиләр.









## Тарга тар дөнья, киңгә киң дөнья

Уку йорты шәхес тәрбияләп чыгару өчен төрле яклап тырышлык куя һәм үзеңне күрсәтү, куйган максатларыңа ирешү өчен КФУда бөтен мөмкинлекләр дә бар. Мәдәни һәм спорт чаралары, форумнар һәм конференцияләр, түгәрәк өстәлләр һәм студентлар активы мәктәпләре студентларга үзләрен төрле яктан ачарга булыша. Шушы максатлардан чыгып, Иҗтимагый студентлар оешмалары һәм берләшмәләренең Координацион советы оештырылды. Аның рәисе булып **Юлия Виноградова** тора. Советка караган оешмалар турында тулырак син 6нчы биттә укып белә аласың. Совет үзе КФУның Яшьләр сәясәте, социаль мәсьәләләр һәм спорт тәрбиясе департаментына (директоры – Ю.Виноградова) карый. Тулырак мәгълүматны уку йорты сайтыннан да карарга мөмкин: **kpfu.ru/studentu/molodezhnayapolitika/koordinacionnyjsovet-obschestvennyh/pervichnayaprofsojuznayaorganizaciya-studentov**

Тел.: 8(843)292-72-70.



## Эш сөйгәнне ил сөйгән

Син әле генә СТУДЕНТ булдың, инде эшкә урнашу, үз хезмәт хакыңа яшәү турында хыялланасыңмы? Ләкин уку белән эшне бергә алып бару бер дә җиңел түгел! Тик шулай да... Сиңа бу мәсьәлә буенча **КФУның Укыту-методик идарәсе Карьера үсеше бүлеге** ярдәмгә килә алачак. Үзең белем ала торган белгечлекнең хезмәт базарында ни дәрәҗәдә кирәкле, нинди вакансияләр актуаль икәнен белешеп, вакытлыча булса да эшкә урнаша аласың. Шулай ук, сиңа биредә вакансияләр ярминкәсе, инновацион проектлар турында да мәгълүмат бирәчәкләр. Моннан тыш, бүлек хезмәткәрләре Карьераны планлаштыру буенча яшьләр үзәге белән хезмәттәшлек итә. Аның әгъзалары булып та КФУ студентлары һәм аспирантлары тора.



Тулырак мәгълүматны Кремль урамы, 18 (төп бина), 165 кабинеттан белешә аласың.

## Иле иркеннең күңеле иркен

Казан федераль университетына укырга кереп, син дус-тату, күпмилләтле һәм күпмәдәниятле коллективка килеп эләгәсең. Ел саен КФУда Кытай, Германия, Казахстан, Эквадор, Бөекбритания, Төркия, Италия һәм башка илләрдән килгән 1500 чит ил студенты һәм аспиранты белем ала. Алай гына да түгел, сиңа лекцияләрне Япония, Франция, Финляндия, Литва, Израиль, хәтта Америкадан килгән галимнәр дә укырга мөмкин. Шуңа күрә сиңа чит илдән килгән студентларга, аларның диненә, мәдәниятенә хөрмәт белән карарга өйрәнергә туры киләчәк. Күпмилләтле мохиттә уку сиңа үзеңә дә үсәргә, чит тел буенча белем-күнекмәләреңне ныгытырга, бөтен дөнья буенча дуслар табарга ярдәм итәчәк.

Әгәр синең стажировка үтү яисә КФУның студентлар алмашу программаларында катнашасың килсә, Тышкы элемтәләр буенча **Академик мобильлек бүлегенә** мөрәҗәгать итә аласың (214 бүлмә, тел. 233-74-67).

Әгәр син чит ил студенты икән, нинди дер сорау борчыса яки проблемаларың килеп чыкса, Тышкы элемтәләр департаментына мөрәҗәгать ит. Ул «иске китапханә» бинасында, төп бинаның ишек алдында урнашкан (Кремль ур., 18, 6 корпус, тел. 233-75-12, kpfu.ru/international ) Ә уку белән бәйле барлык сорауларга (укырга керү, университеттан куылу, стипендия алу, контракт төзү) җавапны син укыту бүлегеннән (113 бүлмә, тел. 233-74-30) ала аласың.





**Ольга Павлова,** Академик мобильлек бүлеге башлыгы




**Сергей Цветков,** Адаптация хезмәте башлыгы



**Римма Галиәкбәрова,** укыту эшләре бүлегенең чит ил гражданнары белән эшләү буенча 1 категорияле белгече

**Сония Ермохина,** паспорт-виза секторының әйдәп баручы белгече





**Адаптация хезмәте** (217 бүлмә, тел. 233-76-16) тулай торакка урнашу, фатир арендалау яисә яшәү өчен яхшы гаилә табарга ярдәм итә. Шулай ук иминиятләштерүгә һәм медицина ярдәме итәргә кирәклеген аңлатачаклар.

**Паспорт-виза бүлеге** (114 бүлмә, тел. 233-76-90) чит ил гражданнарының Россиягә килеп урнашуын контрольдә тота. Миграцион теркәү, визаларны рәсмиләштерү һәм озайту буенча нәкъ бирегә мөрәҗәгать итәргә кирәк.

# СтудНавигатор

### Шартлы билгеләр

- Уку корпуслы
- Филиал
- Спорт корылмалары
- Тулай торак
- Актлар залы
- Китапханә, уку залы
- Студентлар поликлиникасы, сәламәтлек пункты
- Ашханә, буфет
- Wi-Fi зонасы
- Банкомат
- Канцтоварлар
- Почта
- Велосипед кую урыны
- Ашамлыклар кибете
- Велосипед прокаты
- Матурлык салоны

## Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты


*Кремль ур., 4/5*



## Идарә, икътисад һәм финанслар институты

## Өзлексез белем бирү институты

*Кремль ур, 6/20*



## Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

*Татарстан ур., 2*



## Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

## Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты

*Межлаук ур., 3/45*



## Социаль-фәлсәфә фәннәре һәм гаммәви коммуникацияләр институты

## Җәмгыятьнең модернизацияләнүен чагыштырып тикшерү институты

## КФУның Медиа Үзәге

## КФУның Матбугат Үзәге

*Профессор Нужин ур., 1/37*



## Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты

*Пушкин ур., 1/55*



## Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих һәм көнчыгышны өйрәнү институты

*Сул Болак ур., 44*



## Психология һәм белем бирү институты

*Межлаук ур., 1*



## Экология һәм география институты

*Сул Болак ур., 34*



## Физик тәрбия һәм спорт институты

*Оренбург тракты ур., 10*



## «Мәскәү» спортком-плексы

*Мәскәү ур., 49*



## УНИКС

Физик тәрбия һәм спорт буенча гомумуниверситет кафедрасы

КФУның студентлар профкомы

*Профессор Нужин ур., 2*



## КФУның тар

Фундаменталь медицина һәм биология институты


Юридик факультет

Физика институты

Экология һәм география институты

КФУ администрациясе

*КФУның төп бинасы, Кремль ур., 18*



Экология һ
Н.И.Л
Мо

һәм м


Мәгълу
сис

ф
комму

Физика институты

*Кремль ур., 16 а*






1. Төп бина.
2. Ректор бинасы, элек Н.И. Лобачевский яшәгән йорт (хәзер «механичка»).
3. Геометрик корпус.
4. Криоген корпус.
5. Астрономия кафедрасы.
6. Тышкы элемтәләр департаменты.
7. Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханә (иске бинасы), Сирәк китаплар һәм кульязмалар бүлеге.
8. Анатомик театр.
9. А.М.Бутлеров исем
10. Казан Император университетының мед ты лабораторияләрен сы, хәзер КДМУның
11. Көнбатыш ярымц
12. Атом-төш физика се.
13. Көнчыгыш ярымц
14а. УНИКС, мәдәни
14б. УНИКС, спорт

## ихи үзәге



А.М.Бутлеров исемендәге Химия институты
*Лобачевский ур., 1/29*

һәм география институты
Лобачевский исемендәге
атематика һәм механика
институты,
Хисаплау математикасы
мәгълүмати технологияләр
институты,
үмати технологияләр һәм
стемалар югары мәктәбе
Социаль-фәлсәфә
фәннәре һәм гаммәви
уникацияләр институты,
Тел институты
*2 корпус Кремль ур., 35*






мендәге НИХИ.
о
дицина факульте-
ен элекке бина-
3 уку корпусы.
иркуль.
сы лаборатория-
иркуль.
комплексы.
комплексы.

**15**. КФУның «Univer» Медиа-Үзәге Universmotri.ru, «Казанский университет», «Darelfønyn» газета редакцияләре, Матбугат Үзәге.
**16**. ТР Милли китапханәсе.
**17**. Икенче уку корпусы.
**18**. Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханә.
**19**. А.М. Бутлеров исемендәге Химия институты.
**20**. Физика институты.
**21**. Сковородка.

### Фундаменталь медицина һәм биология институты

КФУның Симуляцион үзәге
*К.Маркс ур., 74*



### Фундаменталь медицина һәм биология институты

*Париж Коммунасы ур., 9*



### Фундаменталь медицина һәм биология институты

*Чехов ур., 1а*



### Фундаменталь медицина һәм биология институты

*Волков ур., 18*



### Идарә, икътисад һәм финанслар институты

Инженерия институты
*Бутлеров ур., 4*



### Идарә, икътисад һәм финанслар институты

*К. Маркс ур., 43*



### Инженерия институты

*Сәйдәшев ур, 12*



### «Бустан» спорткомплексы,

*Кулагин ур., 8а*





«Бустан» бассейны

## Яр Чаллы институты

*Яр Чаллы шәһәре, Тынычлык проспекты, 68/19*

Автомобиль булеге
Энергетика һәм мәгълүматлаштыру булеге
Төзелеш булеге
Икътисад булеге
Юридик булек
Социаль-гуманитар булек
Инженер-икътисади колледж



## Алабуга институты

*Алабуга ш., Казан ур., 89*

**Факультетлар:**
Биология
Инженер-технологик
Чит телләр
Тарих һәм юриспруденция
Психология һәм педагогика
Рус филологиясе һәм журналистика
Татар һәм чагыштырма филология
Физик тәрбия
Икътисад һәм идарә
Физика-математика



## Универсиада авылы



Универсиада авылы 45



Теннис академиясе



«Буревестник» бассейны

# Безгә 70 төрле шөгыль дә аз!

**СТУДЕНТ ЧАК – ТОРМЫШНЫҢ ИҢ КЫЗЫКЛЫ ВАКЫТЫ. УЛ ЧОРНЫ УКЫП ТА, ЙОКЛАП ТА, ҖЫРЛАП-БИЕП, УЙНАП-КӨЛЕП ТӘ ЯИСӘ ИЗГЕ ГАМӘЛЛӘР КЫЛЫП ТА УЗДЫРЫРГА МӨМКИН. БУ УҢАЙДАН КАЗАН ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫНДА БӨТЕН ШАРТЛАР ДА ТУДЫРЫЛГАН. МОНЫҢ ШУЛАЙ ИКӘНЛЕГЕНӘ СИН ТОРА-БАРА ТӨШЕНЕРСЕҢ! ӘЛЕГӘ БЕЗ СИНЕ УКУ ЙОРТЫБЫЗДАГЫ КАЙБЕР СТУДЕНТЛАР ОЕШМАЛАРЫ БЕЛӘН ТАНЫШТЫРАБЫЗ.**



### *Хәйриячелек*

- «Мәрхәмәтле кешеләр планетасы» мәрхәмәтлелек үзәге
- «Кояш - балаларга» яшьләр Корчак җәмгыяте
- «Чын йөрәктән» волонтерлык хәрәкәте
- «Аэлита» волонтерлык психология оешмасы

### *Фән*

- Брейн-клуб
- Дискуссия клубы
- Казан нанотехнологияләр клубы
- «Диалог» фән клубы
- «Яшь интернационалист» фәнни түгәрәге



### *Иҗат*

- «Ал Зәйнәбем», «Сәлам», «Зарница» вокаль ансамбльләре
- «Казаным», «Яшьлек», «Индиго» бию коллективлары
- «Tatar style» костюм, «Халык бизәкләре» декоратив-гамәли сәнгать, «Art-дизайн» иҗат студияләре
- «Мизгел» һәм «Ладья» театрлары
- «Әллуки» әдәби-иҗат берләшмәсе










### *Иҗтимагый оешмалар*

- Коррупциягә каршы студентлар хәрәкәте
- Чит ил студентлары ассоциациясе
- Университетта авылы студентлары ассоциациясе
- «Сковородка» сәяси клубы
- Психологлар союзы
- Юридик клуб



### *Туризм һәм хезмәт*

- Патриотик тәрбия үзәге
- «Семь румбов» туристик клубы
- «Снежный десант» эзләү отряды
- Студентларның хезмәт отрядлары оешмасы
- Карьераны планлаштыру үзәге
- Бизнес-инкубатор








### *Спорт*

- Студентлар спорт клубы
- Страйкбол клубы
- Чесбол клубы
- Спелео клуб








### *Куркынычсызлык*

- Студентларның янгын дружинасы
- «Табигатьне саклау хезмәте» иҗтимагый оешмасы
- Студентлар куркынычсызлыгы хезмәте





**КФУ СТУДЕНТЛАРЫНЫҢ БЕРЕНЧЕЛ ПРОФСОЮЗ ОЕШМАСЫНЫҢ ТӨП МАКСАТЫ – СТУДЕНТЛАРНЫҢ СОЦИАЛЬ-ИКЪТИСАДИ, ГРАЖДАНЛЫК ҺӘМ ЗАКОНЛЫ ХОКУКЛАРЫН ТӨРЛЕ ДӘРӘҖӘДӘ ЯКЛАУ. ХӘЗЕРГЕ ВАКЫТТА УЛ ҮЗЕНӘ ПРОФСОЮЗ ӘГЪЗАСЫ БУЛЫП ТОРГАН 9 МЕҢНӘН АРТЫК СТУДЕНТНЫ БЕРЛӘШТЕРӘ ҺӘМ РЕСПУБЛИКАБЫЗДАГЫ ИҢ ЭРЕ ПРОФСОЮЗ ОЕШМАЛАРЫННАН САНАЛА.**



# Безнең белән бул – Профсоюзга кер!





Аннан кала әлеге оешма студентларга үз-үзләрен күрсәтү, коммуникативлык күнекмәләрен алу, лидер һәм оештыручы сәләтен тәрбияләү, үз хокукларын якларга өйрәнү мөмкинлеген дә бирә.

### Профсоюзга ничек керергә?

Моның өчен студентлар Профкомына («УНИКС» концертлар залы, 107-108 бүлмәләр) мөрәҗәгать итәргә кирәк. (Эш көннәрендә 9.00 дан 17.00гә кадәр).

### Социаль туклану

Социаль туклану сменалап оештырыла: ел саен **8 смена** (һәр смена 20 көн (семестрга – 4 смена). Мондый бушлай туклану һәр студентка смена дәвамында тәкъдим ителә (20 төшке аш). Социаль туклану талоннарын алу өчен, гариза тутырырга һәм аны профкомга кертеп бирергә кирәк.

### Электрон кошелек чыгымнарын компенсацияләү

Әлеге ярдәмне алу өчен, гариза тутырырга һәм аңа транспорт картасына 400 сумнан ким булмаган суммадагы акча салыну турындагы чекны теркәргә кирәк. **Ай саен 140 студент 400 сум күләмендә компенсация ала.** Син дә алар исемлегендә була аласың!

### Материаль ярдәм

Бу төрдәге ярдәм көндезге уку бүлегенең бюджет һәм түләүле формаларында белем алучы түбәндәге категория студентларга бирелә:

- **Тулы булмаган гаиләдән булган студентлар**.
- **Күп балалы гаиләләрдән булган студентлар**.
- **Әти-әнисе пенсионер яки I, II группа инвалид булган студентлар**.
- **Студент гаиләләре**.
- **Балалар тәрбияләүче студентлар**.
- **Читтән килеп укучы студентлар** (каникуллар вакытында өйгә кайту чыгымнарын компенсацияләү).

Шул ук вакытта материаль ярдәм студентның җитди авырып китүе, якын туганы үлү, шәхси милкен югалту, бала туу очракларында да бирелергә мөмкин.

### Сәламәт тәндә...

...сәламәт акыл, дип юкка гына әйтмиләр. Шуңа күрә һәрвакыт үз сәламәтлегенне кайгыртып тор. Ә уку йортында хезмәт куючы табиблар синә ярдәм итәр. Көндезге бүлектә укучы студентлар шәһәр **студентлар хастаханәсендә** (Оренбург тракты, 95 – Универсиада авылы), **КФУның сәламәтлек пунктларында** (мәдәни спорт комплексы, 1 этаж; Г.Кутуй урамында урнашкан 6 номерлы тулак торак) дәвалана ала.

### Санаторий-профилакторий

Әгәр син көндезге түләүсез уку бүлеге студенты икән, димәк, син елга бер тапкыр **КФУның санаторий-профилакториенә юллама ала аласың**.

Биредә: **көнгә өч тапкыр бушлай туклану** (Г.Кутуй ур., 2 б адресы буенча урнашкан студентлар шәһәрчеге һәм КФУның физкорпусы ашханәләрендә).

Гомуми савыгу һәм медицина җиһазлары һәм медикаментларын кулланып, **профильле дәвалану**.

**Яшәп тору мөмкинлеге**.

### Билен кысып буган, диләр...

«Әллә каян күренеп тора,солдатта булган, диләр», – дип җырлыйлар. Ләкин бу синең турында түгел, чөнки син әлегә студент һәм армиягә бару турында бу бернинчә ел эчендә онытып торсан да була. Әгәр инде сина Ватан алдындагы бурычыңны үтәргә чакырып хат килгән икән, димәк, син тиешле мәгълүматтан хәбәрдар түгел. Шуна күрә игътибарлы бул!

I курсның көндезге бүлегендә укучы егетләргә КФУның икенче бүлегендә **мәҗбүри хәрби учетка басарга кирәк булачак**. Учетка басу эше КФУның институт һәм факультет җитәкчелегенә хәбәр итүләгә мәгълүматка туры китереп башкарыла. Учетка басу өчен, үзең белән паспорт һәм хәрби-учет документлары – теркәлү турында таныклык яисә хәрби билетны алып килергә кирәк. Учетка баскан кешеләргә, яшәү урыны буенча хәрби комиссариатка тәкъдим итү өчен, **справка** бирелә. Әлеге справка сезне уку дәверендә РФнең Кораллы көчләр рәтенә хәрби хезмәткә алуны кичектереп торачак.

2 бүлек адресы: **М.Межлаук ур., 1 йорт** (керү ишек алдыннан, 3 кат, 302 һәм 306 кабинетлар).

Эш вакыты: **дүшәмбе-җомга, 8.00-17.00**, төшке аш вакыты: 12.00-13.00.

Тел.: **292-22-91**

# Укы һәм «хезмәт хакы» ал!

**КФУ ҮЗ СТУДЕНТЛАРЫ ӨЧЕН МЕНӘ ДИГӘН МӨМКИНЛЕКЛӘР АЧА! СИН БУ УКУ ЙОРТЫНА КЕРЕП, ЗАМАНЧА ҖИҺАЗЛАНДЫРЫЛГАН АУДИТОРИЯЛӘРДӘ ТАНЫЛГАН ГАЛИМНӘРЕБЕЗДӘН ТӨПЛЕ БЕЛЕМ АЛЫП, КИЛӘЧӘК ТОРМЫШЫҢА НЫКЛЫ НИГЕЗ САЛЫП КЫНА КАЛМАЯЧАКСЫҢ, Ә ЯХШЫ УКЫГАН ҺӘМ ҮЗ ТАЛАНТЛАРЫҢНЫ КҮРСӘТКӘН ӨЧЕН, ГОРУР РӘВЕШТӘ «ХЕЗМӘТ ХАКЫ» ДА АЛАЧАКСЫҢ! ШУЛАЙ ИТЕП, СИН ТҮБӘНДӘГЕ СТИПЕНДИЯЛӘРГӘ ДӘГЪВА КЫЛА АЛАСЫҢ:**

✓**РФ Президенты һәм РФ Хөкүмәтенең** махсус дәүләт стипендияләре.

✓**ТРның** махсус стипендиясе.

✓Мәктәп укучылары арасында үткәрелгән бөтенроссия һәм халыкара олимпиадаларда призлы урын алучылар һәм җиңүчеләр өчен **ТР Президенты** стипендиясе.

✓Шәһәр хуҗалыгы, иҗтимагый тармак һәм физика-математика фәннәре өлкәсендә уңышка ирешкән өчен, **Казан шәһәре мэрының** махсус стипендиясе.

✓Уку, фәнни-тикшеренү, җәмәгать эшләрендә, мәдәни-иҗади һәм спорт эшчәнлегендә уңышларга ирешкән өчен, **югары дәүләт академик** стипендиясе.

✓**Оксфорд-Россия хәйрия фонды** стипендиясе.

✓**ТР Фәннәр академиясе** стипендиясе.

✓Урта Азия илләреннән Казан югары уку йортларына укырга килгән татар студентлары өчен, **ТР Фәннәр академиясе** премиясе.

✓Юридик факультет студентлары өчен, **РФ Хөкүмәте булдырган А.А.Собчак ис. шәхси стипендия**.

✓Әдәби иҗат, политология һәм журналистикада уңышка ирешкән студентлар өчен, **РФ Хөкүмәте булдырган А.И.Солженицын ис. шәхси** стипендия.

✓Борынгы Рус мәдәнияте һәм әдәбияты белән бергәттән, филология һәм культурология өлкәләренең фәнни тикшеренүләрендә актив катнашкан студентлар өчен, **РФ Хөкүмәте булдырган Д.С.Лихачев ис. шәхси** стипендия.

✓Югары академик күрсәткечләргә ия булган икътисад факультетлары студентлары өчен, **РФ Хөкүмәте булдырган Д.С.Лихачев ис.** һәм **Е.Т.Гайдар ис. шәхси** стипендияләр.

✓**В.Потанин фонды** стипендиясе (ел саен университеттан 20 яхшы студент билгеләнә).

✓Гидрометеорология һәм экология белгечлеге буенча югары курста яхшы билгеләргә генә укучы студентлар өчен, **«Фобос» фонды социаль** стипендиясе.

✓**«Ак Барс» Банк ААҖ** стипендиясе.

✓Бакалавр, магистр һәм аспирантлар өчен, **British Petroleum** стипендиясе.

✓Ислам тарихын һәм мәдәниятен тирәнтен өйрәнүче КФУ студентлары өчен, **«Ислам мәдәнияте, фән һәм мәгарифенә ярдәм фонды»** стипендиясе.

**Онытма:** КФУ студенты булган һәр кешегә, 1 сентябрьдән башлап, академик стипендия түләнәчәк. Шулай ук социаль стипендия алу мөмкинлеге дә бар.

**Сүз уңаеннан!** Кайбер стипендияләрне хәтта **түләүле бүлектә укучы студентларның да алу мөмкинлеге бар.** Мәсәлән, ТРның махсус стипендиясе; В.Потанин фонды стипендиясе; «Ак Барс» Банк ААҖ стипендиясе.

Әгәр син Бөтенроссия олимпиадаларының призлы урын алучысы яки җиңүчесе икән, КФУга укырга кереп, бер шиксез югары стипендиягә дәгъва кыла аласың. Җиңүчеләр ай саен – **10 мең**, ә призлы урын алучылар **4 мең** күләмендә стипендия алачак.

# Барысы да СИНЕҢ кулда!



**УКЫРГА КЕРҮЧЕЛӘР ИСЕМЛЕГЕНДӘ ҮЗ ФАМИЛИЯҢНЕ КҮРГӘЧ, НИНДИ ХИСЛӘР КИЧЕРГӘНЕҢ ИСЕҢДӘМЕ? БУ СИНЕҢ ӨЧЕН БИК ЗУР БӘЙРӘМ ИДЕ! ӘММА, КЫЗГАНЫЧ, БӘЙРӘМНӘР БИК ТИЗ ҮТЕП КИТӘ ҺӘМ АЛАРДАН СОҢ КӨНДӘЛЕК ТОРМЫШ БАШЛАНА. ӘЛЕ КИЧӘ ГЕНӘ МӘКТӘП УКУЧЫСЫ БУЛГАННАРГА ЯҢА СТУДЕНТ ТОРМЫШЫНА КЕРЕП КИТҮ БИК ҖИҢЕЛ БУЛМЫЙ. ШУЛ УҢАЙДАН БЕЗ СИҢА БЕРНИЧӘ КИҢӘШ ӘЗЕРЛӘДЕК:**

Син – престижлы һәм абруйлы, алай гына да түгел, 210 еллык тарихы, матур традицияләре, ышанычлы бүгенгесе һәм якты киләчәге булган югары уку йорты студенты, шуңа күрә тышкы кыяфәтең, сөйләмең һәм үз-үзеңне тотышың вузыңның дәрәҗәсенә туры килергә тиеш!

Елмай! Яңа коллективта ешрак елмаерга тырыш. Коллективка килеп керү белән, синең турында беренче тәэсир барлыкка киләчәк. Яңа иптәшләреңдә синең хакта ялган образ тумасын өчен, киеренкелек турында оныт!

Үзеңне тәкәббер тотма. Һәр кеше өчен яңа коллективка эләгү көчле кичерешләр белән бәйле һәм синең салкынча мөнәсәбәтеңне тәкәбберлек дип кабул итәргә мөмкиннәр. Шуңа күрә беренче көннәрдә, ничек кенә кыен булмасын, кешеләрдән качмаска, «йомылмаска», контактка барырга, кирәк булса, ярдәм сорарга тырыш.

Төркемдәшләреңә һәм укытучыларыңа карата яхшы мөнәсәбәттә бул.

Коллективны ничек бар, шулай кабул ит. Янәшәбездәге кешеләрне без үзебез теләгәнчә күрергә телибез, ә алар бик төрле: һәрберсенең үз тәҗрибәсе һәм проблемалары бар. Ачуланма, күңелсезләнмә һәм кешене үзгәртергә омтылма! Бу – мөмкин булмаган эш. Сабыр һәм түземле бул.

Иренмә һәм хезмәт ярат! Шуны онытма: син һәрвакыт коллективның күз уңында. Анда синең турыңда туган фикер күп кенә мөнәсәбәт һәм башка әйберләрнең башлангычы булып тора.

Башкаларга ярдәм итәргә тырыш. Әгәр төркемдәшеңнең берәр проблемасы булуын күрсәң һәм вакытың белән мөмкинлегең булса, аңа ярдәм итәргә тырыш. Синең бу адымыңны төркемдәшләр һәм укытучылар һәрвакыт уңай бәяләячәк.

Авыр ситуацияләрдә хәйләләр корма. Безнең капчыкта ятмаганын онытма. Шуңа күрә, хата эшләгән булсаң, башкалар аңлап фаш иткәнче, аны вакытында әйтүең хәерле.

Башкаларны тикшермә!

Әгәр коллективта кечкенәрәк төркемнәргә бүленешне сизеп алсаң, аларга кермәскә һәм бөтен кеше белән дә бер дәрәҗәдә аралашырга тырыш. Моның белән син күп кенә күңелсезлекләрдән качачаксың, чөнки кешеләргә үзгәрү хас.

Беренче көннәрне үк деканатның кайда урнашканын белеш, төркемеңнең кураторы белән таныш. Бу сиңа алга таба төрле мәсьәләләрне оператив рәвештә хәл итәргә ярдәм итәчәк.

Дәресләр тәртибе – ул канун! Тиз арада төркемеңнең расписаниесен язып ал. Мәктәпнекеннән аермалы буларак, университетларда ул үзгәрергә мөмкин, шуңа күрә аңа гел күз салып йөр. Кафедра һәм деканатларның игъланнарын укып бар.

Сессиягә әзерлек беренче дәрестән үк башлана. КФУда баллы-рейтинг системасы буенча укыйлар, ягъни сессиягә билгеле бер күләмдә балл җыйган студентлар гына кертелә. Шуңа күрә беренче көннән үк тырышып укы!

Уку процессының асылына төшенеп, яңа шартларга күнеккәннән соң, университетның иҗади тормышы белән дә танышырга ашык! Монда син күңеленә хуш килгән эш белән шөгыльләнә аласың: иҗтимагый эшләр дисеңме, фән, бию, җыр яисә студентлар әзерли торган чараның оештыручысымы, ә бәлки, син үзеңнең камилләшүеңне берәр спорт төрендә күрәсеңдер? Уңышлар сиңа!

# Беренче курслар өчен календарь!




**Сентябрь**
- Беренче курс студентларының университет җитәкчелеге белән очрашуы
- Студентлар тормышына экскурсия (концерт программасы)



**Октябрь**
- Беренче курслар бәйрәме
- Беренче курслар спартакиадасы
- «Сәлам, талантлар» һәм «Бер адым алга» актив мәктәбе



**Ноябрь**
- Университетның туган көне
- КФУның КВН Лигасы махсус проекты



**Декабрь**
- Ел дәвамында уздырыла торган «КФУның Ел студенты» конкурсына йомгак ясау




**Гыйнвар**
- Студентлар бәйрәме, ягъни «Татьянин день»



**Февраль**
- Сәламәтлек поезды
- Иҗат яшьләренең «Байтик» слеты
- КФУның КВН Лигасы фестивале



**Март**
- Студентлар язы
- «Точка зрения» халыкара фәнни-гамәли конференциясе




**Апрель**
- «Сәламәт тәндә - сәламәт акыл» девизы астында уздырыла торган сәламәтлек көне
- Язгы бал



**Май**
- Җиңү бәйрәме. Уку йортыбыз ветераннарын хөрмәтләү тантанасы



**Июнь**
- Яхшы билгеләргә генә тәмамлаган чыгарылыш курс студентларына кызыл диплом тапшыру тантанасы

DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Махсус чыгарылыш
Тираж 1500

Баш мөхәррир – Илдар Азат улы Кәримов
Иҗат коллективы: Д.Р.Миннекаева, А.Ю.Садыйкова, Л.Х.Исхакова, Р.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева
Фотохәбәрчеләр: В.Михневский, Д.Поварова
Газета бушлай таратыла

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00. «Куранты» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Журналистлар ур., 1, 317.